МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

**06.09.2021** **№ 327**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасының Биектау муниципаль районында төбәк әһәмиятендәге «Казан-Малмыж» – Кыр Станы гомуми файдаланудагы автомобиль юлының юл яны полосаларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының бүленгән полосалары һәм юл яны полосалары турында» 2008 елның 01 декабрендәге 841 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 06 июлендәге 317 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәнең 3.3 пункты нигезендә боерык бирәм:

1. Әлеге боерык (алга таба – боерык) кушымтасына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасының Биектау муниципаль районында төбәк әһәмиятендәге «Казан-Малмыж» – Кыр Станы гомуми файдаланудагы автомобиль юлының юл яны полосаларын билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенә:

боерык чыккан көннән башлап җиде көн эчендә аның күчермәсен муниципаль районның территориясенә карата әлеге боерык чыгарылган җирле үзидарә органына җибәрергә;

боерык кушымталарында күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән махсус файдалану режимы булган зоналарның чикләре турындагы мәгълүматларны Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертелүен тәэмин итәргә.

3. Концессия килешүләре бүлеге җитәкчесе А.М.Шугаловага әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Боерык үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары А.В.Чукинга йөкләргә.

Министр Ф.М. Хәнифов

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы
министрлыгының 2021 елның 6
сентябрендәге 327 номерлы
боерыгына кушымта

«Казан-Малмыж» - Кыр Станы автомобиль юлының юл яны полосалары чикләрендә тулысынча яки өлешчә урнашкан җир кишәрлекләренең кадастр номерлары исемлеге: 16:16:000000:1214; 16:16:000000:363; 16:16:000000:7849(12); 16:16:000000:7849(13); 16:16:000000:7849(2); 16:16:000000:7849(4); 16:16:000000:7849(8); 16:16:050505:12; 16:16:050505:14; 16:16:050505:82; 16:16:050506:36; 16:16:050506:37; 16:16:050506:5

| **Кадастр номерлары исемлеге** | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **т/с** | **Кадастр номеры** | **Җирдән бердәм файдалануның кадастр номеры** | **Кисешү мәйданы, квм.** | **Хокук төре** |
| 1 | 16:16:000000:1214 | | 249.60 | Даими (вакытын чикләмичә) файдалану |
| 2 | 16:16:000000:363 | | 28.47 | Милек |
| 3 | 16:16:000000:7849(12) | | 27824.11 | Милек |
| 4 | 16:16:000000:7849(13) | | 2685.71 | Милек |
| 5 | 16:16:000000:7849(2) | | 31149.27 | Милек |
| 6 | 16:16:000000:7849(4) | | 18387.14 | Милек |
| 7 | 16:16:000000:7849(8) | | 12040.54 | Милек |
| 8 | 16:16:050505:12 | 16:16:000000:141 | 1431.18 | Гомуми өлешле милек |
| 9 | 16:16:050505:14 | 16:16:000000:131 | 13.65 | Милек |
| 10 | 16:16:050505:82 | | 4013.08 | Милек |
| 11 | 16:16:050506:36 | | 6959.02 | Милек |
| 12 | 16:16:050506:37 | | 3687.63 | Милек |
| 13 | 16:16:050506:5 | 16:16:000000:141 | 6907.60 | Гомуми өлешле милек |